

Айнын сонгы атнасында Дубенка районы Ломат авылынын туган якны ойрәнv музее хезмәткәре, традиция буенча, Олкәннәр конеңә багышланган чара vткәргән.
- «Акыллы кешеләр коне» дигән бәйрәмдә без жырлар жырладык, шигырьләр сойләдек, конкурслар vткәрдек, яшьлекне искә тошердек, һәрбер катнашучы алып килгән тәмле ризыклар белән чәй эчтек, - ди әнгәмебездә музей житәкчесе Мәзидә Якуб кызы Муракаева.      Авыл остендә ихтирам яулаган Дубенка районы Ломат авылы ветераннары Советы рәисе, Олылар айлыгына багышлап vткәргән бәйрәм активларына алып килгән грамоталары белән Венера Сәләхетдин кызы Алеева, vзенен ачык кvнеле белән ихластан Сафия Хәмзә кызы Филиппова һәм башкалар авылдашларын жылы котлаганнар. Бәйрәмгә тәмлушкалары белән килгән Нажия Идрис кызы Рахметуллова авылдашларына бик матур жырлар багышлап башкарган, Тәнзилә Айса кызы Бикеева конкурс vткәргән һәм кvнелләрне тибрәндереп кунакларга музыкаль бvләкләр юллаган. Барысы да бик канәгать булып озын-озак аралашканнар, хәтта аерылырга да теләмәгәннәр.
Бу рухи очрашу Ломат авылы олкәннәренен йорәкләрендә озакка истәлек булып сакланып калачак.